ISSN 0136 7110

ЧАЯН



САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ
THE MAGAZINE OF SATIRE AND HUMOUR
12
2001
(CAJAN) CHAYAN
КАЗАН

ШУНДА ХИКМӘТ: «ЧАЯН»НЫҢ БӘЯСЕ ТҮГЕЛ, КӨЛКЕСЕ КЫЙММӘТ!

А. ҮТӘГӘНОВ рәсеме.



Сабантуй кучтәнәче

Динар СӘЛИМОВ

ТӨРЛЕ ҮЛЧӘМДӘ

Күреп, татып фәкыйрьлекне
Бер тугандай без үстек.
Ул чактагы дуслар бүген
Берсе аста, берсе өстә
Төрле үлчәмгә күчтек.

УФА ("Һәнәк").

Хөснулла ТҮЛӘКӘЕВ

БЕР КҮРҮДӘ

— Бер күрүдә гашыйк булдым,—
Дигән була бер сылу.
Алдашадыр, сөйләгәне,
Мөгаен, дим, су кою.
— Андый гашыйк буламы? — дип,
Аптырап сорап куйдым.
Күзгә карап дөп-дөресен
Әйтте бирде бер дустым.
— Юк нәрсәгә исең киткән,
Гашыйк булган дачаңа,
Гараждагы машинага,
Кассадагы акчаңа.
Кайсы бер тутый кошларның
Сиңдәйгә күзе тиз төшә.
Бәгъзе бер агай-эненең,
Ашыгып авыз пешә.

УФА ("Һәнәк").





Л. ЕЛЬКОВИЧ рәсеме.

АЛБАСТЫНЫ ЙӨГӘНЛӘҮ

Булачак Татарстан атом электростанциясе мәйданында 1989 елның көзендә *(кыпме тырышканнан соң!)* кабат бәйсез экспертизалар уздырылды. Аның нәтиҗәләре ТатАЭС проектларының рәсми отчетының 15 пункт буенча тулы нигезсезлеген раслады.

Без бу мәгълүматны укучыларыбыз Татарстан АЭСы төзелеше ябылуга кадәр булган күптәнге вакыйгаларны исләренә төшерсеннәр өчен китерәбез.

Нәкъ шушы елларда безнең редакция тынгысыз Әхмәт Закир улы Закиров белән дуслашты. Бик күп тырышлыклардан соң, ул "Аргументы и факты" газетасында үзенең РСФСР Верховный Советы депутатларына мөрәҗәгатен бастыра һәм аларга Татарстанда, Кама буеның җир асты катламы ярылган урында *(тектоник разлом)* "икенче Чернобыль АЭСы" төзелеп ятуын ирештерә алган иде.

ТатАЭСны проектлау һәм аны төзү мәйданын сайлауны кабат тикшерү рәсми учреждениеләргә һәм хакимият органнарына төзелешне туктату турында карар чыгарырга мөмкинлек бирде.

Күп елларга сузылган бу тарих бернинди рәсми вәкаләте дә булмаган, әмма максатчан, авторитетлы документларга нигезләнеп, башкаларны да үзенә ышандыра алган кешенең никадәрле изге эш башкара алуын күрсәтә.

Әхмәт ага Закиров белән журналист Мөнирә Әпсәләмова әңгәмәсендә нәкъ әнә шулар хакында сөйләнә.

Бу әңгәмә Казанда "Албастыны йөгәнләү яки Татарстан атом электростанциясенең мажаралы тарихы" исеме астында аерым китапчык булып дөнья күрде.

Аның исеме үк сатирик "Чаян" журналына хуш килә. Әхмәт Закиров китапны журналга "ТатАЭСны туктату чорында ярдәме өчен хөрмәтле "Чаян"га", дигән автограф белән бүләк итте.

Р. ТУКТАМЫШЕВ.

ЕЛМАЮ КЕМГӘ ДӘ КИЛЕШӘ

Безнең журнал Татарстанда һәм Россиядә нәшер ителә торган байтак басмалар белән дустанә мөнәсәбәттә. Ә дуслар бер-берсенә юмарт була. Без дә үзебезнең көлкеле иҗат җимешләребездән дусларга бик теләп өлеш чыгарабыз. Каләмдәшләребез исә үзләренең газета һәм журнал битләрендә укучыларына "Чаян" рәсемнәрен, юморескаларын, шигырьләрен һәм мәзәкләрен тәкъдим итәләр.

Күптән түгел дусларыбыз исемлегенә тагын бер күркәм басма — "Известия Татарстана" ("Татарстан хәбәрләре") дигән атналык газета өстәлде. Беренче саныннан башлап аның бит-ләрендә "Чаян" журналы бездә кунакта" рубрикасы даими чыгып килә. Газета исеме белән беркадәр рәсмирәк булса да, Чаян елмаюы бу басмага бик килешле тоела.

Риза ШӘФИ



* * *

Дошманнар жинелер дә китәр,
Мөртәтләр жилегенә үтәр.

ВОТКИНСК шәһәре,
УДМУРТИЯ.

Кәҗә кәбестә бакчасына ничек дәртләнеп керсә, бакча-дача каракларь шуның хәтле хозурланып йорт басалар, бакча малын бүлешәләр.

Амурдагы Николаевск шәһәреннән безнең күптәнге укучыбыз һәм хәбәрчебез редакциягә мондый хат юллаган: "Мин яшәгән поселокта йортыбыз ике фатирлы. Шуның бер ягын дача итеп тоталар. Хуҗалары булдыклы кешеләр. Дача җирендә яшелчә үстерү өстенә, болар тавык-чебеш үрчетергә тотынганнар иде. Шул җан ияләре караклар өчен бик тә кызыктыргыч булып чыкты. Йорт басучылар үстергән бетен кәбестәне, башка яшелчәләрне җыештырып алу өстенә, тавыкларны тотып капчыкка тутырганнар.

Милиция ничектер тиз эш итте. Тавыкларны бездән ерак түгел урнашкан биш катлы йортның бер фатирында таптылар. Биредә күптән түгел төрмәдән чыккан бер адәм актыгы яшәп ята икән. Милиция барып кергәндә әлеге ир затының анасы тавык ите кыздырып маташа икән. Башка тавыкларны, башлары өзелгән хәлдә, балконнан табып чыктылар".

Дача ботарлаучылар әнә шулай тавык ботарларга да күп сорамыйлар шул. Җир читендә — Амур буенда Николаевск шәһәрендә дә шул гадәт, Казан суы, Идел буйларында да әлеге әкәмәт.

Николай Гусаров — безнең Казан бәндәсе — шулай ук нәрсә күрсә шуны ботарлый. Ул "Компрессор" бакчачылыгы җәмгыятенең бер хуҗалыгыннан "Кама" һәм "Школьник" велосипедларын сыптыртып чыга. Ул мунча күрсә, мунча тәрәзәсеннән керә, сарай күрсә, сарайны үтәли тишеп-актарып чыга.

Николай Гусаров үз кулына эләккән теләсә нинди коралны һәм башка кирәк-яракны каптырып чыга. Бакча ботарлау буенча Николай Гусаров, әлбәттә, кәҗә-фәләннән күптән арттырып җибәрде.

Казанда гомер сөрүче Айдар Даутов та "Казанка-2" бакчачылыгының дача тәрәзәләрен тикшереп-барлап йөри. Бусына төсле металлар җыю җәне кагылган. Тәрәзәдән кергән уңайга ул сапер кебек металл эзли башлый. Айдарга 25 тәңкәлек суыткыч аяклары да, күгәрми торган корычтан чәйнекләр дә ярап куя.

Кәҗәгә кәбестә яфрагы ошаган төсле, дача ботарлаучыга нәрсәне булса да электереп чыгу сөенеч китерә, дәртдәрман өсти, күрәсең.

Бакча-дачаларның ике аяклы кәҗәләре әле тегендә, әле монда пәйда булалар.

Әнә узган ел Урман хуҗалыгы министрлыгына караган "Дубок" бакча-



чылыгының унлап дачасын ботарлап чыкканнар иде. Быел әлеге кәҗәләр, иске юлдан килеп тагын "Дубок"ны чемчеп йөриләр. Бу юлы прокуратура хезмәткәре йортын да кызганып тормаганнар.

Гомумән, карак кәҗә гадәтле бәндәләр бакча хуҗасының кем булуын әллә ни аерып тормыйлар. Прокурор, милиция хезмәткәре бакчасын басу аерата дуамаллык кузгатып, каннарын кыздырып җибәрә кебек.

Эчке эшләр министрлыгына караган "Радуга" бакчачылык җәмгыяте хуҗалыкларыннан барлык төсле металл әйберләрне җыеп чыгарга да күп сорамадылар угры кәҗәләр.

Бакчачыларның мунча мичләрен сүтү дисеңме, базга төшеп, җәһәннәмгә яшергән әйберләрне актарып табу дисеңме, тегеләр бөтенесенә дә сәләтле.

Васильевога бара торган поездда миңа ике аяклы кәҗәләр белән бәйләнгән әллә нинди әкәмәтләр ишетергә туры килә. Берсендә танылган язучы Роза Хафизованың савыт-сабасын, балта-пычагын ничек яшереп азаплануы хакында кыйсса бәян иттеләр.

Язучы беркемдә булмаган фантазиясен алтын-көмеш һәм алюминий савыт сабасын җен-пәриләр таба алмаслык җиргә яшереп бетергән. Әмма ике аяклы кәҗәләр җен-пәриләрдән дә тапкыррак булып чыкканнар. Хәзер Роза Хафизова шул явыз тапкырлар турында хикәят язып тәмамлады һәм аны "Чаян"га юллады.

Мәгълүм булганча, "Чаян" бакча корткычлары турында беренче генә тапкыр сүз йөртми.

Узган елгы бер фельетон буенча республика прокуратурасы шактый гыйбрәтле мәгълүматларны гомумиләштерде.

Республика прокуроры урынбасары Фәрит Заһидуллин редакциягә җибәргән җавабында Республикада 1221 бакчачылык булып, дача хуҗалыкларының 405 меңнән артып киткәнен күрсәтә. Шушы хәтле бакчачының ел саен 1000 тирәсен бутап чыгалар (бусы теркәлгән караклык исәбе генә!).

Бакча мөлкәтенә кызыгучы ике аяклы мөртәтләрне табып алу, җинаятьне ачу күрсәткечләре яхшыра дип тә раслыйлар.

Әмма бакча кәҗәләренең дә сизгерлеге-осталыгы артканнан арта бара, күрәсең.

Кешеләрнең бакча тирәсендәге мөлкәтен саклау буенча махсус милиция төркемнәре оештырган очраклар бар.

Бакчачылык җәмгыятьләре аеруча күп булган районнарның администрация җитәкчеләре, хокук органнары белән берлектә, сыналган ысулны кулланып, кешеләрнең хәләл хезмәте белән булдырылган мөлкәтен саклауны гына оештырырга кирәк, билгеле.

Бакча-басарларны бакча карачкысы белән генә өркетеп булмаска охшаган.

Р. ФАТИХОВ.



В. ЛЕПХАНОВ рәсеме.



М. ФРОЛОВ рәсеме.



Шәмәрданнән ГАЛӘВИН

"Чаян"да басылган табышмаклар һәм мәзәкләр ахырында сез аның фамилиясен еш күрәсез.

"Чаян" өчен көлкеле мәзәкләр һәм табышмаклар эзләп аңа бөтен Советлар Союзын йөреп чыгарга туры килә.

Хәзер, поездларга һәм самолетларга бәяләр котырып үскәч, Галәвин күбрәк Шәмәрдән бистәсе белән Казан шәһәре арасында килеп сара. Редакциягә килгәндә бервакытта да буш кул белән килми.

Ул — күптән "Чаян"ның үз кешесе, атаклы Шәмәрдәндә безнең кеше.

Шәмәрдән бистәсе, мөгаен, Галәвин аркасында бөтен Рәсәйгә шулай нык танылгандыр.

Ренат Галәвин бүген укучыларга үзенең яңа язмаларын, шул исәптән усал фельетонын да тәкъдим итә.

Р. ФАТИХОВ.

Галәвингә — миллион

Мин бервакыт, "Книга — почтой" фирмасына шахмат уены турында китапларга заказ җибәреп, зур ахмаклык эшләдем. Китаплар килде. Ләкин алар дуңгыз симертү һәм люцерна үстерү турында иде. Шуннан соң миңа берсеннән-берсе калын хатлар килә башлады. Мәсәлән, Мария Дюваль миңа "Календарь удачи" һәм "Гороскоп-ясновидец" дигән китаплар җибәрергә вәгъдә итте. Сез, кем соң ул Мария Дюваль, дип сорасагыз, хәтерегезгә төшерәм: бу ханым турында кайсы телләрдә генә язмадылар, ә бөтен дөньяга танылган 700 ләп басма әлеге француз күрәзәчесен мактап мәкаләләр бастырды.

Менә шул Мария Дюваль, миннән тарала торган дулкыннарны *(белгечләр аларны флюидлар дип атыйлар)* сизенеп алып, миңа: "Якындагы елларда, хәтта айлар эчендә сезне беркайчан да булмаган уңайлы чор көтә", дип язды. Моның өчен 349 сум, шуңа өстәп заказны эшкәртү чыгышлары исәбенә тагын 39 сум акча түләсәм, мин тиздән миллионер буласым икән, чөнки "Спортлото", "Спортпрогноз", "Золотой ключ" уеннарының иң зур отышлары миңа эләгәчәк! Әмма минем миллионер буласым килмәде, шуңа күрә акча да җибәрмәдем. Шулай да, күрәсең, минем флюидларым әлеге ханыма тынгылык бирмәгәндер — тагын хат килеп төште. Тик нишләптер хатлар әлеге яманаты чыккан медиум яши торган Франциядән түгел, ә ташкалабыз Мәскәүдән иде. Адресы да бик кыска: абонент ящигы, 5. Озак та үтмәде "Шанс" исемле финанс программасыннан да, миңа уенда катнашырга *(бушлай түгел, әлбәттә)* һәм җилдән килгән 300 мең сум акчага ия булырга тәкъдим ясап, янә бер хәбәр иреште.

Күптән түгел генә миңа килгән биш битлек тагын бер хаттан көтмәгәндә үземнең Мәскәүдәге "Клуб Почта" ОООсының әгъзасы икәнлегемне белдем. Аның хатлар җибәрү филиалы Тверь шәһәрендә икән. Миңа килгән хатта тантаналы төстә болай диелгән иде: "Котлыйбыз, Галәвин әфәнде! Сез бүген суперпризга — 150 мең сум акчага ия булдыгыз!" Бу яңалыкны укыгач аз гына аңымны югалтмадым. Башкача әйтсәм, инфаркт кичерү хәлендә идем. Булса да булыр икән кешене шушы чиккә җиткерү!

Әмма ләкин бу сумма минем капчыкта *(шул хәтле акчаны тагын кая саласың инде)* булсын өчен мин нибары 500 сумлык заказ бирергә тиешлемен икән. 24 битлек каталогта 23 төрле крем, препарат һәм китап исемнәре күрсәтелгән иде. Мәсәлән, чәч һәм тырнаклар өчен "Нутрикап", аякларны матур һәм сәламәт тоту өчен "Венокомфорт", эч күбенүдән "Эффидижест" препараты. Һәркайсының бәясе дә 99 сум гына. Ә хатын-кыз имиләрен тырпаеп, тыгыз итә торган "Золотая тайна" крем-коктейле нибары 349 сум тора.

Китаплардан "Победить боль в спине", "Уроки знаменитого сексолога", "Лечение без лекарств", "Лекарства без врача" һәм башка шуларга охшашлары тәкъдим ителә. Һәр китап 299 сум тора. Әйе, шуннан һич ким түгел. Шулай итеп, капчыкка әлеге 150 мең тәңкәне салып кую өчен мин, 4485 сум акча түләп, 15 китапның бөтенесен дә сатып алырга әзер булырга тиеш икәнмен.

Мине тагын бернәрсә сагайтты. Хатка өстәп язылганча, мин, каталогтагы тауарларның кимендә берсен сайлап, аның хакын түләсәм, "Суперприз"да отышка хокук алам. Аерманы сизәсезме? Отышны үзен түгел, ә аңа хокук алам. Бу хокукка ия булу-булмау, кем әйтмешли, сәнәк белән крем-коктейльгә язылган. Менә нинди бәхеткә ия буласы кеше икәнмен мин!

Тагын гаҗәпләндергәне шул булды: Мария Дювальдә дә, "Клуб Почта" ОООсында да миңа берүк номерны сукканнар — 11995167... Ышанып әйтә алам, отыш турында бер мин генә түгел, ә Суперпризга өмет баглаучы меңнәр хат-хәбәр алгандыр.

Шәхсән үзем, иманым камил, бик тиз ышанучан кешеләр исемлегендә йөрим. Шуңа күрә миллион вәгъдә итүчеләргә көч-хәл белән карышып исән һәм үземнең тиеннәремне саклап кала алганмын икән, киләчәктә, белмәсәң, күктән төшкән миллиард-бәхет астында сынып-сытылуым да бар.

Ренат ГАЛӘВИН.

***

Герасим "Титаник" корабы капитаны янына килеп, болай ди: — Этемне корабыгызга алмассызмы?

Р. ГАЛӘВИН.

Шәмәрдән бистәсе,
ТАТАРСТАН.

ҮРТӘМЕШ

Ренат Галәвиннән сорагаңнар...

— Әйт әле, ахири, иләк белән чиләк арасында нинди аерма бар?

— Шуны да белмәскә... Иләктә су тормый, ә чиләктән акмый.

***

— Мөдәррис Әгъләмовта ул юк та, файдаланмый да, ә Зөлфәттә бар һәм ул аннан файдалана. Бу нәрсә?

— Әйтсәм әйтим инде... таяк!

***

— Ир-ат белән хатын-кыз нәрсәсе белән аерыла?

— Ир-ат кышын да, җәен дә ыштаннан йөри, ә хатын-кыз җәй җиткәч ыштанын салып ташлый.


***

— Чит телдә төш күрсәң нишләргә?

— Аптырагансың икән — йокыңнан бүленеп сүзлеккә ябышырга!

М. ФӘЛӘХОВ.

Нәстәләрдер Лап-лоп Оча




И. АЗИМОВ рәсеме.



М. ФРОЛОВ рәсеме.



В. ТАРАСЕНКО рәсеме.



А. ЛЕВИТИН рәсеме.



В. СУМАРОКОВ рәсеме.



В. АЛЕКСАНДРОВ рәсеме.



А. АЛЁШИН рәсеме.



«Чаян»ның КОСМЕТИКА САЛОНЫ

София Гобәйдуллинаның ЮБИЛЕЕ

Якташыбыз композитор София Әсгат кызы Гобәйдуллинага быел 70 яшь тула. Казанлылар түземсезлек белән аның кунакка кайтуын көтә. Башкалабызда аның исемендәге фестиваль узачак.

София Гобәйдуллина — XX гасырда бөтен дөньяда дан казанган бердәнбер хатын-кыз композитор. Ул әле күп кенә дәрәҗәле халыкара бүләкләр иясе дә, Россиянең "бөек өч" композиторының (Гобәйдуллина — Денисов — Шнитке) берсе дә.

Менә ун еллап инде София ханым Германиядә, зур шәһәрләрдән еракта урнашкан кечкенә генә бер авылда яши, читкә бик чыгып йөрми. Үзенең әйтүенчә, бөтен килере музыка язудан.

Казанга соңгы кайтуында аңардан еш кына татар телен белү-белмәвен, әсәрләрендә милли хисләрнен бөтенләй диярлек булмау сәбәпләрен сорадылар. София ханым туган телендә беraз сөйләшә булып чыкты. Ә икенче сорауга композиторның җавабы болайрак иде: бар милләтне күтәргән художниклар, бар милләт күтәргәннәре...



Салонда **Надежда КАРТАШОВА** елмая. КАЗАН шәһәре.

МӘҖЛЕСТӘ ОЧРАШУ

Хуҗабикә соңга калып килгән кунагын табындашларга тәкъдим итә икән:

— Таныш булыгыз — Нәгыймә. Хәбирнең җәмәгате.

Хәбир дигәннәре кырыкка җитеп яңа өйләнгән эшмәкәр икән. Бу мәҗлестә Хәбир тирәсендә чуалгалаган бер ханым да булган.

— О! Җиңелмәс крепостьны алган генералны тәбрик итәм, — дигән ул, киная белән.

— Сиңа да ныклабрак һөҗүм итәргә иде, — дигән Нәгыймә.

— Мин начар стратег шул. Чигенә белмим. Әсир булып кына төшәм. Хәер, әсирлекне артыграк күрәм, — дип кунакларны көлдереп алган җор телле хатын.

ТОРМЫШ СЕРЕ

Ике ханым очраша. Берсе яшерәк, икенчесе шактый өлкән. Хәл-әхвәл белешеп тора болар.

— Ирем бер дә булышмый. Өйдәге бар мәшәкать үземдә, — дип зарлана яшерәге.

— Ирләр алар скрипкә кебек шул. Башта әйбәтләп көйләргә кирәк үзләрен, — ди тәҗрибәлесе.

— Ни эшләргә кирәген беләсез инде сез, — дип куя яшь ханым.

— Белмичә! Скрипкә генә түгел! Зур бер оркестр бар безнең өйдә. Барысын да җайлар өчен беләсеңме нинди дирижер булырга туры килә.

— Күз алдыма китерәм, — ди яшь ханым, авыр сулап.

Ләбибә ИХСАНОВА.



БӘБИ: "ИШЕТӘСЕЗМЕ МИНЕ, АЗГЫННАР?!"

Алты ай була инде монда әүмәкләнеп ятканыма. Тынычлык кирәк иде дә миңа, кая инде ул?! Бертуктаусыз шаулыйлар, сүгенәләр, тәмәке тарталар, аракы эчәләр. Кая эләктем соң мин, шайтан алгыры?! Ну, чыгыйм гына моннан, күрсәтәм әле күрмәгәннәрен мин ул хәшәрәтләргә!..

Ой, нишләптер күптән тәмәке тартмыйлар, бер-ике суырсаң, мишәйт итмәс иде. Ихтимал, минем аркада тартмыйдыр инде ошбу корсак иясе. Әһә-ә, исенә төште, ниһаять. Вәт, кәеф әйбәтләнеп китте ичмасам! Инде йокласам да ярыйдыр шәт. Юк, нишләптер йоклап булмый. Ашыйсы килә. Әй, син, миңа ризык бирәсеңме бүген, юкмы? Тиз бул, юкса тешлим үзеңне. Әһә, тәгам килә башлады... Фу, тәмсез! Мин бит яратмыйм мондыйны! Миңа тагын начар булачак бит инде. Әй, син, хет алма ташлар идең, яки бераз сөт! Ә бусы ни тагын? Ә-ә, хәмер! Хәзер берсәк кенә кәгәм дә йоклыйм. Юк, йокларга ирек бирмиләр, азгыннар! Әй, ни кыланасыз анда, оятсызлар? Сытасыз бит мине! Монда бүтән бәби кирәк түгел, үземә дә кысрык, ишетәсезме? Ну, кәне, әй! Әгәр дә мәгәр мине һаман шулай мыскыл итәләр икән, чурту-матыр тугыз аемны тутырмыйча чыгам! Срогымнан алда чыгам да күрмәгәнегезне күрсәтәм әле мин сезгә, азгыннар! Минем тууыма гына түгел, үзегезнең ник туганыгызда да үкенерсез!..

Наил ГАБДЕЛХАКОВ.

КАЗАН шәһәре.



С. ПРИВИНА рәсеме.

Роза ХАФИЗОВА

БОРГАЛАНМА!

Очрашканда ачылмыйсың
Йөзен карангы, көек.
Сүзләреннен дә тәме юк,
Чүбек чәйнәгән кебек.

Әрле-бирле койрык болгап,
Нидер кылгандай итеп,
Ник башым әйләндерәсең,
Бер килеп тә бер китеп?!

Әкият сөйләгән буласың,
Чынга охшаган итеп,
Алдашасың пачум зерә —
Торам исләрем китеп!

Тәмам гажиз булдым жаным
Тойгысыз мәхәббәттән.
Өстемнән тау төшәр иде,
Коткарсаң бу афәттән.

Дүрт ягың кыйбла, жанашым,
Тинсез бәхеткә тиен!
Боргаланма кылдый-былдый!
"Сөймимен!"— генә диген!

Анатолий ЧУДИНОВ

САКАЛ

"Ни өчен хатын-кызга сакал чыкмый? — дип эчтән генә фикер йөртте караңгы чырайлы Кульков, үзенең ияген кырыну өчен крем белән күбекли-күбекли. — Һәр көнне менә шулай кырынып карасыннар иде алар, шул чакта аңлар иде алар ир-атның хәлен... Хәтта юк, алар кырынмаслар иде барыбер. Киресенчә, сакалларын озын итеп үстерәчәк алар, төрле төстәге тасмалар белән үреп яки бөдрәләтеп йөри башлаячак. Әле сакалларына төрле төстәге брошкалар да тагулары бар..."

Кульков үзенең хатынын әнә шундый кыяфәттә — озын сакалына тасмалар, брошкалар таккан килеш күз алдына китерде дә жирәнеп лач иттереп төкерде: "Юк, хатын-кызга сакал килешми икән. Иң яхшысы сакалсыз йөрсеннәр!"



Журнал укучыбыз Мәзәк сөйли

Танк өйрәнүләре бара. Командир рациядән әмер бирә:

— Беренче танк! Алга!

Танк кузгалып китә.

— Икенче! Алга!

Икенчесе дә алга ыргыла.

— Өченче! Алга!

Әмма монысы урынында тик тора. Һәм аннан күзләре акайган танкист чыга:

— Вәйт әкәмәт! Боларның бүрекләре сөйли белә икән ич!

Е. ЕГОРОВА.

КАЗАН.

* * *

Яңа бүлмәгә күчкән түрә бик тә эре кыяфәттә өстәле артында утыра. Ишек шакыйлар. Хужа кеше керергә рөхсәт бирә, үзенең югары урын биләвен күрсәтергә тырышып, телефон төребкәсен ала.

— Әйе, генераль директор әфәнде, мин бүген шофер белән очрашачакмын, сезнең күрсәтмәләрегезне аңарга һичшиксез житкерермен. Миңа әйбәт теләкләрегез өчен рәхмәт. Исән булыгыз. — һәм ишек төбендә торучы хезмәткәргә эндәшә:

— Сезнең ни йомыш?

— Телефоныгызны төзәтергә кердем...

А. ГАЗИЗОВ.

БАШКОРТСТАН.

* * *

— Бездә шартлар бик әйбәт. Эштән чыккач, йөгереп китәсең дә, кыядан диңгезгә сикерәсең — һәм бах!

— Сез, бултыйх, димәкче идегездер?

— Су күтәрелгән чакта, әлбәттә, бултыйх!

* * *

— Акчаңны чыгар!

— Акчам юк минем.

— Сәгатеңне сал!

— Сәгатем дә юк.

Талаучы теге агайның жилкәсенә асылына.

— Алайса әнә күрше урамга илтеп куй!

* * *

Балалар кардан кеше ясап куялар. Бер кыз бала:

— Аның кайбер нәрсәсе житми бит, — ди.

Малай:

— Нәрсәсе житмәгәнен мин беләм. Хәзер алып киләм.

— Икене алып кил. Борыны урынына да кишер куярбыз.

* * *

— Кеше гомеренең өчтән бер өлешен ятакта уздыруы мәгълүм хәл инде. Ә калган ике өлешен ничек уткәрә икән?

— Эшлидер, ял итәдер инде. Ниндидер шөгыль табадыр үзенә.

— Дөп-дөрес әйттең! Ул калган вакытын кемне дә булса ятакка егып салу белән үткәрә!

В. АМРЕМОВ.

ЛЕСОСИБИРСК.





ӨЙГӘ ЭШ

XV гасырда тавык йомыркасы ярдәмендә азартлы-комарлы уен белән мавыкканнар. Колумб йомыркасы дигән мәгълүм тарихның чыганагын да шуннан эзләргә кирәктер, күрәсең.

Уенда икәү катнаша. Алар шакмаклы тастымалга бер үк зурлыктагы йомыркаларны чиратлашып куялар. Өстәлгә бер куйганнан соң, йомырканы күчерергә дә, хәтта аңа орынырга да ярамый. Уен тастымалда йомырка куярлык шакмаклар беткәнчегә кадәр дәвам итә. Йомырканы иң соңыннан куйган кеше откан санала. Тастымалның зурлыгы төрлечә, ирекле булганлыктан, кемнең бәхете баса, шул җиңәр шикелле. Әмма бер зирәк адәм уенны беренче булып башлый да, һәрвакыт җиңә бит, оттегенәсе. Бөек диңгез сәяхәтчесе билгеләп үткәнчә, әлеге адәм уенның "бик гади булган сратегиясен-хәйләсен" тапкан.

Йале, сез дә уенны беренче башлап, отыш яулап карагыз әле.



ТАБЫШМАКЛАР

1 Алтын хуҗа кырга чыгып бакты,
Көмеш көтүче кырдан чыгып качты.

2. Каядыр чаба Наташка,
Күлмәкләре катлы-катлы.
Җил исте дә хатынның
Итәкләре ачылды.

3. Бии-бии әйләнеп,
Күбрәк әйләнгән саен
Юанаядыр гәүдәм.

С. МАЗУРОВ.

СМОЛЕНСК шәһәре.

4. Бәхәстә кайчан хаклык табыла?

Р. ГАЛӘВИН.

ШӘМӘРДӘН бистәсе,
ТАТАРСТАН.

5. Сәясәт — пычрак эш булса, сайлаулар нинди көн соң?

6. Иң сәләтле кош нинди була?

7. Нәрсә ул сәнгать?

С. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.

КАЗАН шәһәре.

ҖАВАПЛАРЫ:

1. Кояш һәм Ай. 2. Тавык. 3. Орчык. 4. Хатын-кыз катышканда. 5. Мунча кәнә. 6. Җимне җиргә төшкәнче үк эләктерә торганы. 7. Күп корбаннар бирә торган урын.



И. НӘФИЕВ рәсеме.



А. ЛЕВИТИН рәсеме.



М. АБДЮШЕВ рәсеме.



Тискәреләргә — авызлык

Сөйләсәң адәм ышанмаслык хәл: фатир алганнан соң да, элек яшәгән тулай торактан китәргә теләмәүче тискәре бәндәләр дә очрый икән бу дөньяда. Андыйлар әлеге табигый булмаган теләкләрен суд аша гамәлдә калдырырга телиләр хәтта.

Юк, биредә хикмәт урын алыштырырга куркудан да, уртак кухня, уртак туалеттан файдалануга күнегүдән дә түгел. Барысы да бик гади: әлеге тискәре бәндәләр алган фатирлары өстәвенә тулай торактагы яшәү мәйданнарын да "шәхси милекләре" итеп калдырырга телиләр.

Мисал өчен, "Чистопольстрой" ОАОсының тулай торагында А. Гатауллин дигән инсан яшәде. Моннан ике ел элек үзе эшли торган предприятие аңа льготалы бәягә ике бүлмәле фатир бирде. Инде моннан соң акчаңны түләп, ордер алгач, яңа ояңа кереп утыр да рәхәтләнеп яшә югыйсә. Әлегәчә торган бүлмәне бушатырга дип язма рәвештә бирелгән вәгъдәсе дә бар бу гаиләнең. Әмма эш алай гына, гади генә хәл ителми икән шул. Яңа фатирга ия булып алган хуҗа тулай тораккагы бүлмәне калдырып китәргә катгыян теләми. Җәмәгать торагын ул үзенә мирас итеп бирелгән дип уйлагандыр, күрәсең.

Шактый гына үгетләгәннән соң, А. Гатауллин яңа фатирына күченде ниһаять, әмма ләкин әлеге "мирасын" сакларга тулай торак бүлмәсендә хатынын һәм кызын калдырды. Тиздән ул, үзенә калса, җиңелмәслек һөҗүмгә күчте: үзе эшли торган предприятиедән эштән китеп барды. Бернинди сәбәпсез. Янәсе, хәзер миңа бәйләнә алмассыз! Әмма хәйләкәр бер нәрсәне исәпкә алмаган булып чыкты: әгәренки сәбәпсез-нисез эшеңнән үзең теләп китәсең икән, сине фатир бирмичә дә тулай тораккан чыгарып җибәрә алалар.

А. Гатауллин белән көрәшеп арган "Чистопольстрой" ОАОсы дәгъва белән шәһәр судына мөрәҗәгать итте. Һәм суд мәсьәләне җентекләп тикшергәннән соң, А. Гатауллинны тулай торактагы ябышып яткан бүлмәсеннән чыгарырга дигән карарга килде. Дәреслекне эзләп Республика Югары Судына мөрәҗәгать итү дә әлеге карарны үз көчендә калдырылуы белән тәмамланды. Ниһаять, өченче власть тискәрелеккә авызлык кигезде...

Тиздән акыллы баш А. Гатауллинның дәвамчысы да табылды. Бу юлы ведомство торагын үзенеке итәргә теләүче Н.Тарасов дигән инсан иде. Ул да нәкъ менә әлеге алымнар белән эш итә башлады. Аның һәр гамәлен А. Гатауллин күзәтеп, үз киңәшен биреп тора дип уйларсың, валлаһи.(Аерма тик шунда гына: Тарасов өч бүлмәле фатир алды.) Хәлбуки, аның алымнары да уңыш китермәде. Суд ошбу тискәрене дә элек яшәгән бүлмәсеннән яңа фатирына озатты.

Шунысын да әйтергә кирәк: суд коллегиясендә рәислек итүче Р. Шакирҗанов, теге яки бу кешегә фатир биргәнче, тулай торак хуҗаларын аларның алдагы гамәлләрен яхшылап өйрәнергә, җәмәгать милкен үзләренеке белән бутамаслыкларына ышанганнан соң гына, яңа фатирга ордер бирергә чакырды.

Әмма ләкин ни гаҗәп, үзендә эшләүчеләрнең торак мәсьәләсен яхшыртырга теләгән предприятиеләр суд каршында җавап бирүчеләр булып кала бирәләр, яңа фатир алучыларны элеккеге ояларыннан чыгара алмыйча иза чигәләр.

Казандагы район судларының берсе, мәсәлән, балалар йортында үскән Ж.ны тулай тораккан чыгарырга дип карар кылды. Ж.ның ордеры да, пропискасы да бар иде. Аның гаебе шунда: ул коммуналь хезмәтләр өчен 1900 сум бурычлы икән. Моннан тыш, аның тулай торакта калуына комендант каршы икән. Тагын бер дәлил: Ж. хәрби учетка басмаган булган. Хәлбуки хәрби учет мәсьәләсендә комендантның ни дәхеле бардыр инде? Әйтүе кыен.

Бу очракта Татарстан Югары суды Ж.ны яклап калды. Ул район судының Ж.ны тулай тораккан чыгарырга дигән карарын хаксыз гамәл дип бәяләде.

Шулай булгач, борчылмыйча яши бир, егет! Тик моннан соң коммуналь хезмәтләр өчен түләргә һәм хәрби учетка басарга онытма. Ягъни мәсәлән, үзеңне берзәнбер торак урыныннан мәхрүм итәргә теләүчеләргә сәбәпләр булмасын. Менә шул.

А. МӨХӘММӘДИЕВ,
Р. ИСМӘГЫЙЛЕВ.



Фәтхи БУРНАШның
сөйкемле догасы

Минем бүгенге сүзем «Чаян» журналын оештыручыларның берсе һәм аның тәүге редакторы Фәтхи Бурнаш хакында.

Без укыганда бу әдип мәктәп программасында юк иде. Педагогика институтында мин каләмем белән физика-математика фәне коесын казыдым. Хәтта олгая башлагач та, Фәтхи Бурнаш кебек шәхеснең бөеклеген, талант колачының киңлеген, җәмгать эшчәнлегенең күләмен һәм файдасын тою һәм бәяләү миңа җиңел түгел. Әмма Фәтхи Бурнаш иҗатыннан һәм аның турында язылган хезмәтләрдән бик үзенчәлекле бер ягын ачык сизәм: әдипнең остазлары — аның белән замандаш, иптәш, ә шул ук чордашиптәшләре — аның остазлары. Ул дәвернең талантлары менә шулай бер-берләреннән өйрәнеп, бер-берләрен өйрәтеп, бер-берләренең кимчелек-җитешсезлекләрен күреп, яшерми әйтеп иҗат иткәннәр: Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Мирхәйдәр Фәйзи, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Мәҗит Гафури, Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Нәкый Исәнбәт...


Актриса **Фатыйма ИЛЬСКАЯ**, әдипләр **Фәтхи БУРНАШ**, **Әхмәт ЕРИКӘЙ**, **Муса ҖӘЛИЛ**. 1934 ел.

Фәтхи Бурнашның гыйлемлелеге, таланты, иҗат эшенә сәләте кайдан килә? Ул — Закир мулла малае. Фәтхелислам 1898 елның 1 гыйнварында Чувашиянең Батыр районы, Кикшик авылында туа. Казандагы Мөхәммәдия мәдрәсәсендә укый. 1916 елда учительская школа өчен имтиханнар тапшыра. Шәкерт чагында ук "Сәйяр" театры, аның җитәкчесе Габдулла Кариев, драматург Кәрим Тинчурин белән таныша. 1928 елдан Татар дәүләт академия театрында директор.

Атаклы драматург, күренекле шагыйрь, ялкынлы публицист, танылган театр тәнкыйтьчесе Фәтхи Бурнашның журналистикадагы хезмәтләре дә бәяләп бетергесез. Бу өлкәдәге эше 20 яшендә Сембер шәһәрендә "Көн" газетасында редактор булудан башлана. Казанга килгәч, "Кызыл Армия", "Татарстан хәбәрләре", "Безнең байрак" газеталарында, "Безнең юл" һәм "Чаян" журналларында редактор булып эшли. Әдәбият-сәнгать белеменә һәм тәнкыйтенә кагылышлы биш йөздән артык мәкалә-рецензия яза.

Шушы басмалардан бүгенге көнгә кадәр фәкать "Чаян" журналы гына исемен дә үзгәртми, йөзен дә бозмый, кыйбласын да хыянәт итми чыгып ята. Чөнки аңа сөйдергеч догасын Фәтхи Бурнаш үзе укыган, олы юлга фатихасын Фәтхи Бурнаш үзе биргән.

Бөек шәхесебез бу дөньядан фаҗигале төстә 1946 елда китеп бара.

Аннан безгә гаять бай мирас калды. Әдип хезмәтләре бүгенге көндә дә актуальлеген бер тамчы да югалтмаган. Хәзер килделе-киттеле җырлар җырлап йөрүчеләргә гыйшык тоткан яшь йөрәкләргә менә бу юллары үрнәк түгел мени?! "Яшь йөрәкләр" пьесасында Сәйфулла җырын тыңлыйк:

Кызарып кояш чыгадырлай,
Белмим кайда бата икән?
Ак беләген ястык итеп
Җаныем кайда ята икән?
Аңа егетләр кушыла:
Кыйгак-кыйгак кыр казлары
Китә көзләр җиткәндә.
Бу кыз бала ник назлана
Кочып-суырып үпкәндә?..

Бүген мин укучы игътибарына "Илһам" комедиясеннән Җәмилә белән Шәриф диалогын, "Әҗәл" поэмасыннан өзекләр тәкъдим итәм. Шунысы кызык, Әлдермеш Әлмәндәренә кадәр, 1919 елда ук, Фәтхи Бурнаш Әҗәл белән бер солдатны тартыштырган булган икән бит, әй! Әдип "Татар сәхнәсе" дигән рецензиясен "Татарстан" газетасында 1922 елның 13 сентябрь санында "Номерсыз урындык" дигән псевдоним белән бастыра. Театр тәнкыйте, гомумән әдәбият-сәнгать тәнкыйте юкка чыккан хәзерге заманда аның да бер кисәге белән танышу зыян итмәс.

Мәгъсүм ГӘРӘЕВ.

ИЛҺАМ

...

Шәриф. Ә беләсеңме, мин бу юлларны язганда кемне уйладым?

Җәмилә. Кемне?

Шәриф. Минем илһамчым, минем алиһәм, минем музам бер генә... Мин шуны уйладым.

Җәмилә. Ә ул кем?

Шәриф. Ул кем, дисеңме? Ул минем алиһәм, музам, ә аның икенче исеме... Җәмилә.

Җәмилә. Ах, әгәр дөрес булса...

Шәриф. Минем күңелемдә, Җәмилә, бары бер син генә...

Җәмилә. Ах, нинди күңелле, нинди күңелле...

Шәриф. Җәмилә, беләсеңме нәрсә?

Җәмилә. Нәрсә?

Шәриф. Моннан соң мин синең исемеңне һичбер вакыт Җәмилә дип телгә алмаска телим...

Җәмилә. Әбәү! Нәрсә өчен? *(Үпкәли.)*

Шәриф. Мин сине, илһамым дип кенә йөртәсем килә.

Җәмилә *(аңлап, шатланып)*. Шулаймы?

Шәриф. Әйе... син шуны теләмәс идеңме?

Җәмилә. Ах, нинди прелесть!

Шәриф. Илһамым! Музам!

Җәмилә. Нинди күңелле, муза!.. *(Көйләп.)* Муза, муза, музыканты...

Шәриф *(сөеп)*. Илһамым!..

Җәмилә. Ах, мин синең шундый ил-





һамың булырмын, син бөтен дөньяны үзеңнең поэзияң белән чолгап алырсың...

Шәриф. Әлбәттә, әлбәттә! *(Сөеп.)* Син бүген тагын да матурлана төшкәнсең!..

Җәмилә *(Шәрифне диванга утыртып)*. Шулаймы?

Шәриф. Бүген бу кечкенә аякларың тагын да зифарак күренәләр...

Җәмилә *(сөеп)*. Шулаймы? *(Торып.)* Мин сиңа шундый илһам бирермен... Ух! *("Па"лар ясый.)* Там-та-тара-ра-рам... рас! Алай да син минем аякларым турында һичбер шигырь язганың юк... Тамтара-ра-рас!

Шәриф. Мин, әлбәттә, язачакмын... Әллә никадәр язачакмын. Алар шундый матурлар!..

Җәмилә. Шулаймы? Там-тара-ра-рас! Безнең балетмейстер Казанский да әйтә... Җәмилә туташның аяклары классически матур аяклар, ди... Рас!

Шәриф. Нәрсә?

Җәмилә. Бер көнне антрактта ул мине үзенең уборныена алып керде дә... рас!

Шәриф *(гаҗәпләнеп)*. Нәрсә? Уборныена?..

Җәмилә. Әйе... Аякларымны карады... рас!

Шәриф *(гаҗәпләнеп)*. Ничек карады?

Җәмилә. Үлчәп карады... рас!

Шәриф. Балетмейстермы?

Җәмилә. Әйе... икрасыннан, аннан тездәнрәк үлчәп карады... рас!

Шәриф. Ә?

Җәмилә. Сезнең аякларыгызның пропорциясе бик дөрес, ди... рас! Классически аяклар, ди... рас! Киләсе сезонда бары сезнең аякларыгызга багышлап кына бер балет куям, ди... рас!

ӘҖӘЛ

ВАКЫЙГАДА БУЛУЧЫЛАР:
Солдат.
Әҗәл.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әҗәл.
Бетте гомрең, әй егет!



Д. БЫКОВ рәсеме.

Солдат.
Чү!
Әҗәл.
Бетте гомрең, пәһлеван!
Солдат.
Чү, сабыр!
Әҗәл.
Юк, гайре мөмкин түгел.
Солдат.
Ник болай соң син түземсез?
Әҗәл.
Мин түземле, мин вәкил.
Солдат.
Кит! Килмә син.
Килмә син, мин бит үләргә
Уйламыйм һич, мин торам,
Мин торам, алда рәхәт,
Шат гомер итәргә омтылам.
Әҗәл.
Юк, егет, юк, бетте гомрең,
Чикле гомрең, бел, бала,
Һичберәүгә ихтыяр юктыр
Торырга дөньяда.

....

Солдат.
Соң нигә мөмкин түгел?
Мин дә бит торган адәмнәрнең
Береннән ким түгел.
Ник миңа салкын кабер дә,
Ник алар соң шатлана?
Әҗәл.
Монсы, егетем, билгеле түгел
"Үзеннән" башкага.
Солдат.
Юк, түгел, барсын беләм мин,
Монда бер сер бар, беләм.
Ник минем бәхтем түгел бер
Илдә калганнар белән?
Ник минем күкләр йөри сөргендә
Аһ-ваһлар белән?
Илдә калганнар нигә соң
Типтерә ярлар белән?
Ник минем гөлдәй гомерләр
Үтте хәсрәт, зар белән?

....

Әҗәл.
Ялгышасың, әй егет, син,
Мин барам да Тәңредән
Ярдәм сорыйм, миһләт сорыйм.
Солдат.

....

Син әгәр солтан, илаһлардан
Вәкил булсаң, ашык —
Мин шуларга каршы сугышучы!
Ерак бул, әйдә чык!
Әҗәл.
Чү, егет, чү! Нинди сүз бу?
Бу миңа? Бит көчле мин.
Солдат.
Көчле син, синнән дә көчлерәк
Булырга мин телим.
Әҗәл.
Нинди гафләт бу, егет, ах,
Нинди хәсрәт бу сиңа!..

....

Июль, 1919.

«Таһир-Зөһрә»

8 нче сентябрьдә шул ук Большой театрда Камал II һәм Г. Камалларның бенефисенә "Таһир-Зөһрә" куелды. Таһир ролен Камал II уйнады.

Ләкин ул Таһир роленә дорфарак булганын күрсәтте. Алай да уртача яхшы башкарып чыкты.

Г. Камал *(Габдулла Камал, ягъни Камал I турында сүз бара. М. Г.)* вәзир ролендә йомшак иде. Зөһрә ролендә Байкина чибәр уйнады. Хан ролендә Колмәмәт, гаскәр башы ролендә Мостафин ярыйсы иделәр.

Ханчаны уйнаган Казанская вәкарьле, усал (...) ханча урынына безгә вак табигатьле (...) татар хатыны тибын бирде.

Бөтен уйнаучыларның электән килгән бер начар яклары бар: алар, әлбәттә, Таһир-Зөһрәне дә, Йосыф китабы укыгандагы кебек, җөмлә бету-бетмәүгә карамастан, һәрбер юлның ахырында тыныш ясап, тавышны шул җирдә өзеп такмаклап сөйләргә яраталар. Моннан соң бу бетерелергә, нәзым белән язылган әсәрләр дә нәсер шикелле үк сөйләнергә тиеш.

"Фәтхулла хәзрәт"тә халык бик күп, "Гашыйк гариб" һәм "Таһир-Зөһрә"дә дә күп иделәр.

P. S.: Егерме беренче гасыр башында ук Чаян абзыебызны котлап, чәкешәсе, өченче меңьеллыкның да буеннан-буена аның күкрәп яшәве һәм исәнлеге өчен тостлар тотасы көннәр бар икән бит әле. Уйнап әйтү түгел, моңа матур сәбәпләре күренеп тора. Быелның декабрендә журналның 1500 нче саны чыга. 2002 елның соңгы көне тәмамлану белән үк "Чаян"ның нәшер ителә башлавына төп-төгәл 80 ел тулып куя.

"Чаян" архивына кереп чумырга җыенуыбызның сере менә шуларда. 1500 нче сан чыгар алдыннан журнал редакциясендә эшләгән язучы-шагыйрьләрне янәдән бер кат барлап, шул чордагы иҗатларына күз салып алырга булдык. Шаккатырлык. Тәгәрәп үсәннәр икән алар "Чаян"да. Күрәсең, Фәтхи Бурнаш, Һади Такташ һәм Мирсәй Әмирнең аягы җиңел булган. Шагыйрь Әхмәт Исхак та биш ел "Чаян"ны җитәкләп бара. Шагыйрьләр Зыя Мансур һәм Шәрәф Мөдәррис, прозаиклар Габдрахман Минский, Газиз Мөхәммәтшин, Габделхай Сабитов, Фаил Шәфигуллин безнең редакциядә эшләгән. Бүген көндә исән-сау булган язучы Альберт Яхин шактый еллар редактор иде, Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев, халык шагыйрьләре Шәүкәт Галиев һәм Илдар Юзиев, Тукай премиясе лауреатлары драматург Туфан Миңнуллин, шагыйрьләр Марс Шабаев һәм Зөлфәт, язучылар Батулла, Барлас Камалов, Вахит Монасыйпов, Мәгъсүм Хуҗин, Камил Кәримов... "Чаян" мәктәбендә укыйлар.

Бәлки, кайберәүләрнең хәтер сандыгында алар тормышыннан "Чаян" белән бәйле истәлекләр бикләнеп ятадыр. Искә төшерик "Чаян"да тәгәрәп үсәннәр" дигән рубрикада.



* КОНКУРС * КОНКУРС * КОНКУРС * КОНКУРС



Кәҗәсе түгел — мәзәге...

Хулиганнар бер танышымның тешен коеп кайтарганнар. Теш куйдырырга барса, ике мең сум акча түләргә кирәк икән. Ә аның ике мең түгел, ике сумы да юк чагы. Авызымны ачсам үпкәм күренер дип, иренен кысып йөри хәзер. Эш хакын түләмәсәләр дә сүз әйтми, базар бәяләре күтәрелсә дә дәшми. Фатир хакын арттырсалар да кычкырмый. Рәхәт тешсезләр белән эш итүе.

Ләбибә ИХСАНОВА.

КАЗАН.

Туксанда теш төшәр,
Йөздә яңадан тешәр.

Мәкаль.



Э. ДАНТЕС рәсеме.

Маннур САТТАРОВ

КАДЕР һәм ҖӘБЕР

Тау башында яткан асыл ташны
Төлке балалары тараткан.
Исемегезне мактап телгә алгач,
Кадер күрдем Сезнең тарафтан.
Тау башында яткан асыл ташны
Бүре балалары тараткан.
Исемегезне каклап телгә алгач,
Җәбер күрдем Сезнең тарафтан.

Нәкыйп КАШТАНОВ

ЯҢА ФАТИР һӘМ МИЧ

Куаныштык сеңелем белән
Дөньяларыбыз матур.
Бирделәр безгә бу җайдә
Өр-яңа иркен фатир.

Кояш төшкән бүлмәләре
Безгә көлеп карыйлар.
Миче юк, ә батарейлар —
Гармуннар күрегедәй.

Көз килүен сизмәдек тә,
Суынды өй — йөткертә.
Югарыдан әмер килгән:
— Ягарга әле иртә!

Эх безнең элекке фатир,
Мичено яга торган,
Югарыдан хәбәр көтми
Утыны яна торган.

Акшарларын коймый гына
Алып килик шул мичне:
Назласын җылысы белән
Иркәләсен һәр кичне.

ЧАЯННЫҢ шәфкать фәрештәсе

Кемнәрнең туган көне апрельгә туры килә? Кем алар? Җор күңелле, шук кешеләр, әлбәттә. Кем булсын? — юмор журналы "Чаян" хезмәткәрләре, әлбәттә!

Әйткән сүз рас килде: Ләйлә Тәхтиеваның юбилей көне нәкъ 1 апрель икән бит, җәмәгать. һәм "Чаян" коллективы көлке көнендә үзенең ветеранының өенә барып, хәлен белеште.

Ләйлә апа каләмдәшләрен колач җәеп, шаян сүзләр сөйләп һәм, әлбәттә, мул табын көйләп каршы алды.

Сыйланган арада без аның тормыш юлын күз алдыбыздан кичердек. Чистай төбәгенең Каргалы авылында туган кыз япь-яшь килеш Ленинград каласына китеп бара. Сугыш елларында үзенең газиз Казанына эвакуацияләнеп кайта. Аннары йәнә Ленинградка китә. һәм, кияүгә чыгып, Казанга кайтып төпләнә.

Ленинградта уку һәм яшәү сатирик "Чаян" ("Скорпион") журналында эшләгән елларда Ләйлә ханымга бик тә ярдәм итте. Журналның тәрҗемә вариантын бар итү еллары иде бу.

Шулай итеп, Ләйлә ханым үз гомеренең утыз елдан артыгын юмор һәм сатира эшенә багышлады, редакциянең ачык, киң күңелле, юмарт хуҗабикәсе булды, чаянчыларның берничә буынын тәрбияләп үстерүгә күп көч куйды.

Ләйлә ханым татарчадан русчага тәрҗемә иткән хикәяләр "Чаян"-да туктаусыз басылып чыга торды. Татарстан китап нәшрияты нәшер иткән китапларга керде.

Ләйлә Тәхтиева җөмһүриятебезнең Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Чаян үзенең Ләйлә Тәхтиева, Г. Вәлиев, С. Оффенгенден, И. Хантимеров шикелле үз эшләренең чын осталары туплаган тәҗрибәсе белән көчле!

Шарж сурәте осталары — рәссамнар тынгысыз Ләйлә апабызны сурәтләү өчен ярыша-ярыша иҗат иттеләр. Аның сурәтен тарихи итәргә тырыштылар.

Иseme нәмәгълүм бер рәссам ясаган шаржга күз төшерегез — кем хакында сүз барганын бер карауда ук аңларсыз!

һәрвакыт күңелегез шат һәм шаян булсын, янгызда "Чаян" булсын, Ләйлә апабыз!

Рәшит ЗӘКИЕВ.



ҖИРДӘ



В. СУМАРОКОВ рәсеме.

Д. ПОЛУХИН рәсеме.





В. ЩУКИН рәсеме.

Ю. БЕЛЯЙЧЕВ рәсеме.



А. КЛИМОВ рәсеме.



Художник колонкасы







Э. ДЫШАЕВ рәсемнәре.

ЧУАР ПРЕССА

ЧИТ ХАТЫНГА КҮЗ АТСАҢ...

Жан-Клод Ван Даммның үз көндәшләрен бик җиңел генә егып салуын кем генә күрмәгәндер. Ул — экранда йодрыклары һәм аяклары белән көрәш остасы. Күптән түгел шулай Париж рестораннарының берсендә бераз төшереп алган Ван Дамм хатын-кызларга бәйләнә. Бу вакытта шул ук ресторанда КПРФтан яшь депутат Андрей Скоч та була. Голливуд супермены аның хатынына бәйләнә башлагач, Скоч аны кисәтә. Моңа ачуы килгән Ван Дамм Россияне һәм россияннарны хурлау сүзләре ычкындыра. Ә Андрей, хатыны һәм Ватаны намусын яклап, суперменга алагаем сугып, аны идәнгә аткара. Ван Дамм, аңына килеп, үзенең сакчыларын чакыртып ала, төпәләшү башлана. Бокс буенча атказанган спорт мастеры Андрей Скоч исә Ван Даммны нокдаунга озата, сакчыларын, самбо алымнарын кулланып, тузгытып ташлый. Тәмам уңышсызлыкка очрап, җиңелмәс киногерой чигенергә һәм депутаттан гафу үтенергә мәҗбүр була. Ярый әле Ван Дамм безнең братвага туры килмәгән, югыйсә, бәрелеш контроль ату белән дә тәмамланган булыр иде.



ЭЧМӘ — ЭТ БУЛЫП ӨРЕРСЕҢ...



Рәсәй шәһәрләренең берсендә яшәүче Альберт Ибраһимовның бик начар, эштән өенә исереп кайту гадәте булган.

Әйе, бу гадәт Россиядә киң таралган. Хатыны һәм әбисе Альбертның бу гадәтеннән туеп беткәннәр икән. Моның әбисе бер им-том итүчедән аракыдан "биздерү даруы" рецептын белешкән. Аракыга эт тизәген кушып эчерсә, кияве шайтан суыннан бизәр дип өметләнә әби. Кияү дә хәйләкәр булып чыга, хатын-кызларның яшерен серләшүен тыңлап тора. Беркөнне эшеннән аек кайтуына кияүне өстәлдә кайнар аш янында сургучлы шешә көтә. Әбисе кухняга чыгып кергән арада Альберт Мөҗитович шешәне үзенекенә алыштыра.

Әби кияүгә ягымлы да, илтифатлы да, аракыны да стаканга коеп кына тора. Кияү дә бик ачык. Ул шаяртып алырга ниятли — эт булып өреп куя. Куркуыннан әби йокы бүлмәсенә сыпырта, ә Альберт дүрт аякланып, эт кебек һаулап аның артыннан... Карават астына кереп качкан әбинең арт ягын кияү тешләп ала. Әбигә — инфаркт, шаянга — җиде ел төрмә. Кайберәүләр аракы эчүдән менә шулай котылалар.

ЙОКЫСЫЗЛЫКТАН ДӘВА

Әмрикалы Джим Миллер Нью-Йоркта туган һәм үскән. Калифорния яры буена күчеп яши башлагач, бу йокысызлыктан интегә. Моның сәбәбе океан дулкыннары тавышыннандыр дип уйлый ул. Төнге зур шәһәр тавышлары язылган кассетаны тоташтырып куюга ул тынычлап йокыга тала. Джимга саф диңгез һавасы белән дә көрәшергә туры килмәгәе әле. Моның өчен караваты янында бер чиләк бензин куеп йоклау иң яхшы чара булуы ихтимал.





Үтемле
ТАУАР

Ике журнал — бөтенроссия басмасы "Чаян" (CHAYAN) һәм бөтендөнья басмасы "Ридерз Дайджест" (Reader s Digest) — яшьтәшләр, аларның чыга башлавына тиздән 80 шәр ел тула.

Безнең журналлар һәм аларның укучылары — күптәнге дуслар. Чаянчылар үзләре чәй эчкәндә балны әлеге журнал редакциясе бүләк иткән көмеш кашыклар белән чөмчиләр. Ә "Чаян"ны яратучылар десертка "Ридерз Дайджест"ны укыйлар, кайберләре исә хәтта аның отыш уеннарында да катнашалар. Узган 2000 елда, мәсәлән, аның бер уенында гына катнашып егерме ике якташыбыз акчалата һәм әйберләтә бүләккә лаек булды.

Шулай да "Ридерз Дайджест"ның иң кыйммәтле призлары "Чаян" өлешенә тия. "Чаян" мәзәкләре һәм көлдергечләре әлеге журналның "Көлү — иң яхшы дару", "Дөньяда ниләр генә булмый", "Мундирлы юмор" кебек рубрикаларында даими басылып килә.

"Чаян" да чыккан ике мәзәк "Ридерз Дайджест" аша Америкада нәшир ителгән мәзәкләр җыентыгына да сайлап кертелде. Бөтендөнья юмор базарында үтәрлек тауарың булу әйбәт шул!

Бүген сезгә "Ридерз Дайджест" журналы битләрендә басылган "Чаян" мәзәкләренең кайберләрен тәкъдим итәбез.

М. ФӘЛӘХОВ.

* * *

— Мин велосипедлы булырга хыялланам! Саф һавада педаль әйләндерү бик файдалы дип, иремнең тәңкәсенә тиям.

— Ул теләгеңне үтәдеме соң?

— Өлешчә. Тегү машинамны балконга чыгарып куйды.

* * *

— Син мине быел уналты мәртәбә алдадың, — дип үчекли хатыны ирен.

— Уналты мәртәбә түгел, унбиш тапкыр, — дип ачулана ире. — Яратмыйм ялганчыларны.

* * *

— Соңгы мәртәбә сорыйм: кайчан миңа әҗәтегезне кайтарасыз?

— Бу ахмак сорауны соңгы тапкыр бирүегезгә мин бик шат.

* * *

Цирк директорына бер ир-ат эт ияртеп килә.

— Сезгә уникаль номер тәкъдим итәм, — ди ул. — Мин этемне скрипкада уйнарга өйрәттем. Паганини сонатасын да башкара.

— Акылдан шаштыгызмы әллә?! — ди директор. — Скрипка концертлары тыңларга кем циркка йөри инде?!

* * *

— Сез миңа ботинкаларымны бүген төзәтеп куярбыз дип ышандырган идегез.

— Әйе шул. Ике сум акчагызны түләгез.

— Нишләп бик аз? Квитанциядә ремонт дүрт сум тора дип язылган бит.

— Дөрес, шулай. Әмма без сезнең бер ботинкагызны югалттык.

З. ХӘКИМОВ рәсеме.



— Бу көмүне оештырган спонсорларга зур рәхмәт!



В. МИЛЕЙКО рәсеме.



* * *

Италияле көндәлегенә болай дип язып куйган: "Кичә кич буе бер рус агае белән аракы эчтем. Үлә яздым. Бүген көн буе аның белән ук баш төзәттем. Их-х, кичә үлгән булсам икән..."

* * *

Ир белән хатын спектакль карыйлар. Беренче пәрдәдән соң, ир бәдрәфкә чыгарга тели. Ике рәт арасыннан иплән кенә уза да бәдрәфне эзләп китә. Сәхнә җиһазлары куелган урынны таба да шунда йомышлый. Урынына килеп утыргач, хатыныннан:

— Икенче пәрдәнең күп өлешен күрмичә калдыммы? — дип сорый.

— Борчылма! Син анда төп рольне башкардың!

* * *

Ишек шакыйлар.

— Кем бар?

— Әйтегез әле, сез гел өйдә буласызмы?

— Әйе. Нигә кирәк бу сезгә?

— Болай гына... Социологик тикшерү-сорашу бу...

* * *

Әтисе белән улы автоинспектор булып эшлиләр.

— Улым, тор, эшкә соңлыйсың.

— Ә сәгать ничә?

— Жиденче ярты.

— Иртә ич әле!

— Иртә ди синң! Инде ярты сәгать машиналар бушка йөри!

* * *

Бер агай курортта танышкан сөяркәсенә:

— Сезнең белән беренче очрашкан көннән бирле,— ди,— ни ашый, ни эчә, ни тарта алмыйм...

— Мине шулай бик нык яраттыгызмыни?

— Юк ла, боларга акча житми башлады!

* * *

— Сездә крокодиллар бармы? — дип сорый зоокибеттә берәү.

— Бар.

— Ә кечкенәләре, буе метрдан кыскалары?

— Андыйлары да бар.

— Ә бик тә кечкенәләре, шырпы тартмасы буелары?

— Бар. Аласызмы?

— Ала алмыйм, барыбер куркыныч инде ул крокодил дигәнең...

* * *

— Сезгә операция ясадыларммы инде? — дип сорый табиб авырудан.

— Әйе.

— Ничек соң?

— Өч мең доллар!

— Юк, мин, сездә нәрсә иде, дип сорыйм.

— Бер генә мең иде.

— Юк ла инде, нәрсәгә жаловаться иттегез?

— Түләү кыйммәтлегенә инде.

АЙГА-ЕЛГА БЕР

"Йорт салу — эт оясы корып кую гына түгел" — дип юкка әйтмиләрдер. Татарстан Республикасының Эчке эшләр министрлыгы карамагындагы төзелеш-монтаж идарәсендә (СМУ) моны аңлап бетермиләрме, әллә инде онытып җибәргәннәрме, һәрхәлдә Глазунов урамындагы сигезенче йортка карагач, нәкъ шундый сорау туа.


Сиксәненче елда ук төзелә башлаган әлеге бинадан фатир бирүләрен көтә-көтә көтек булган МВД хезмәткәрләре инде картаеп пенсия яшенә җиттеләр. Ә пенсионерлар белән, үзегез беләсез, вакланып маташмыйлар. Моның шулай икәнлеген без үз җилкәбездә татып инандык. Көннәрдән-бер көнне төзүчеләр, ниһаять, тантаналы рәвештә фатирларыбыздан ачкычлар тапшырдылар. Бу минутларда бездән дә бәхетле кеше булмагандыр, мөгаен. Әмма иртәрәк сөенгәнбез икән. Фатирларыбызга кергәч "аh" иттек: ишек-тәрәзәләре кыек-мыек. Аллам сакласын, җир тетрәү-мазар була калса, бөтен йортың ишеләчәк тә төшәчәк. Моның өчен биш балл да җитә. Идәннәр җәелмәгән, обойлар ябыштырылмаган. Бу эшләрне тәмамлау үз кесәбездән булачагын әйтеп, төзүчеләр безне тагын бер кат "куандырдылар".

Җитмәсә, чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, Идел буе районының 74 нче ЖЭУсы да фатирга теркәлү өчен сигез йөзәр сум таләп итте. Шунысы кызык — җан талашып сатулашучыларны бер тиенсез дә теркәделәр, теркәвен.

Ишегалдында балалар мәйданчыгы төзелмәгән. Лифт эшләми. Унынчы катка кадәр җәяү менү әби-бабайлар өчен уен эш түгел, югыйсә. Шуңлыктан урамга һава суларга да айга-елга бер генә чыгабыз.

Глазунов урамындагы
сигезенче йортның I подъездында яшәүчеләр.

КАЗАН.



В. ФЕОКТИСТОВ рәсеме.



Мәгъсүм Гәрәевнең мут хикәятләре

Алтмышынчы еллар башында Казан каласына чех, немец сыралары килә башлады. Алардан авыз итү өчен зур блат кирәк. Миндә бар ул. Сәүдә министры Мингали Исмәгыйлев белән якыннан таныш мин, дус яшибез. Китабын язып биргән идем. Чит ил сыралары елга портына килә. Шундагы ресторан складыннан гына җибәрәләр. Официанткаларны, шешәләрнең матур этикеткаларын куптарып алып, өстәлгә китерергә өйрәттем.

Җәйге эссе көннәрнең берсе иде. Тәмле, салкын сыра эчәсе килеп китте. Елга портына үземә генә бару күңелсез, иптәш эзлим. Ләкин, ни хикмәттер, бу кичтә радиода ир-ат затыннан берәү дә калмаган. Ялгызым гына китеп бардым. Иделгә карап, суда акчарлаклар шикелле, салмак кына йөзүче ак теплоходларны күзәтә-күзәтә, ашыкмыйча гына бушатам этикеткасыз шешәләрне. Әстерхан воблАсы белән рәвешен китереп, хушланып, тәмен белеп эчәм. Рәхәт, күңел күтәренке. Сыраның кәефе мигә дә йөгерә, күрәсең. Мәгълүм ки, андый чакта башка кызык-кызык уйлар килә.

Радиода диктор Эльс Гаделев кичке якта минем иркемә, теләгән җиремә бара алуыма көнләшеп карап калган иде. Ул бүген эшен унда бетерә. Кызык итим әле үзен.



Ул чорда хәзерге дипломатларга охшаш кечкенә калын чемодан тотып йөрү модада иде. Аны калдырган юк. Хәзерге моментта бигрәк тә кирәге чыкты. Алты шешә чех сырасы алып салдым да радиога кайттым. Башта әллә нинди хыялый хәйләләр. Камал театры (хәзерге Тинчурин театры) радио белән янәшә. Почмагында туктап калдым, план корам. Теге шешәләрне театр бинасы түбәсеннән яңгыр сулары ага торган торба эченә тутырсам?! Шулай эшлим дә, торба каравылчысы булып басып торам. Эльсның чыгуын көтәм. Әнә килә. Мин да аңа таба берничә адым атладым.

— Кайтып китмәгән идең мени?— ди Эльс.

— Киләсе атнада зур тапшыруым бар. Шуның текстын язып утырдым,— дип алдыйм тегене.

— Яхшы иткәнсең. Шулкадәр күп укыдым. Авызым тәмам кипте. Их, бер шешә салкын сыра!

— Табабыз,— дим мин әтәчләнеп.

— Таптың ди, көндез булмаганны, төнлә?

— Була дигәч була инде. Тик шарты бик катгый. Мин әйткәннәрнең барысын да кушканча, төп-төгәл үтисең.

— Шапырынма сана!

— Менә сиңа чемодан. Аны ачып, әнә теге торба астында җиргә тиермичә ике кулың белән ныклап тотып тор. Мин, йөгереп килеп, торбага тибәрмен. Аннан шешә-шешә чит ил сырасы агар!

Эльс, эче катып, көлә.

— Әкият сөйләмә, акты ди, тот капчыгыңны!

— Хәзер әкияттәге тапкыр егет кебек җиргә тибеп җирдән йомырка салдырган шикелле итәм,— дим.

Китә Эльс торба янына чемоданын тотып. Торбага кагылуым була, дөбер-дөбер шешәләр коела.

— Менә бу фокус, ичмасам, Гәрәев фокусы! — ди диктор дустым Эльс, гайрәтен чәчеп, бу кызык, мәкерле гамәлемә шаккатa.

— Фокус икән фокус булсын. Киттек, алайса, Фукс бакчасына,— дим шук эшемнең барып чыгуына канәгать булып.— Чех сырасын ай яктысында шунда эчәрбез.

ТОТ КАПЧЫГЫҢНЫ!

Җиһаншинаның әтисе булам!

Бөекләр белән эшең төшмәсен. Йә авызларыннан бер сүз тартып ала алмыйсың, йә телләре телгә йокмый. Ул кәперәюләре, ул хәйләкәрлекләре!

Җырчы Валентина Пономарева, чегән романсларын үзәккә үткәреп башкарып, бөтен Европа гашыйклары йөрәгендә ут кабызып кайткач, шәпләнеп-эреләнеп киткән, кыяфәтләре тәкәбберләнгән. Ни генә булмасын, гаҗәеп әйбәт җырлый, чукынчык! Абыйсы Владимир скрипкасына кушылып җыр сузганда йөрәкне кыеп-телеп, тәнеңдәге җаныңны, сөягеңдәге җелегеңне суырып-сыгып ала. 2000 елның 13 октябрендә безнең Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында нибары бер концерт бирде. Залда халык исәпсез-хисапсыз, урамда калган тамашачылар, әгәр рөхсәт итсәләр, люстраларга асылынып тыңларга-карарга риза. Зал, мәхәббәт дигән могҗизалы-тылсымлы дөньяның татлы хыяллары белән сихерләнеп-шашып, дәррәү күтәрелеп кул чаба.

Шушындый талант иясе белән очрашып сөйләшә алмауны мин гөнаһ санаyим, булдыксызлык дип бәялим. Җырдан-җырга мине кыздыра бит бу кыз.


Валентина ПОНОМАРЕВА.

— Сезнең Казаныгызда да миндәй җырчылар үсә. Юлия Җиһаншинаны чакырыйм әле. ОРТ каналы үткәргән Бөтенроссия конкурсында кызыгыз лауреат булды. Тыңлагыз! — ди Пономарева тамашачыларга мөрәҗәгать итеп.

Суза романсын Юлия. Без хәйран калып тыңлыйбыз. Белми йөргәнбез. Үзебезнең музыка училищесын тәмамлаган. Мәскәү танымыйча, үзебезнекеләр оялып торган. ФедорТютчевның "Ангель мой" дигән шигыренә музыкасын да Казан консерваториясе укытучысы Виталий Харисов язган. Менә дигән романс килеп чыккан.

Валя сәхнәгә романслар сөючеләрне чакырып кына тора. Имзасын салып пластинкалар, открыткалар өләшә. Һәркайсының милләтен сорый.

Шуңа күрә Пономарева белән сөйләшергә теләгем көчәя бара. Тәнәфестән соң киттем сәхнә артындагы бүлмәсенә. Мөләем генә бер ханым ишек төбендә юлымны бүлде.

— Валентина Пономарева берәү белән дә очрашырга теләми...

Миңа җаен табарга кирәк.

— Мин Юлия Җиһаншинаның әтисе булам! — дим режиссер ханымга.

— Кереп әйтеп карыйм!

Бәхет баса. Яшь җырчының әтисен күрми калу килешмәс.

Тиз борылды режиссер.

— Ике-өч минутка гына мөмкин, — ди.

Миңа бер минут та җиткән.

— Сез сәхнәгә менүчеләрдән барысының да милләтен сорадыгыз. Колакларына гына әйткән сүзегезне беләсем килгән иде...

Җырчы ачык кеше, иркен күңелле икән.

— Мин татар композиторы Рөстәм Яхин романсларын да яратам. Татар балаларына Рөстәм Яхинны җырларга куштым. Шәп зәвыкны романслар җырлап, романслар тыңлап бергәләп тәрбиялик.

Валентина Пономарева минем Җиһаншинаның әтисе түгел, бәлки журналист икәнлегемә төшенгәч, аптырап, гаҗәпләнеп карап торды:

— Ата журналистлардан качып котылам димә...

АЙ, ЯРАТКАН БАЛТАМ...

Күз җитеп, бакча сезоны беттеме, бакчачының башына уй төшә: бакча мөлкәтеңне, йорт-җиреңне караклардан ничек сакларга? Мин дә узган көз, үземчә, караклардан саклану чарасын күрдем. Савыт-сабадыр, чиләк-чүмечтер кебек әйберләрне мунчага ташып куйдым. Каракларны кызык итим әле, мин әйтәм, мунчага кереп йөрмәсләр, "байлыгымны" шунда тутырыйм. Әмма бик каты ялгыштым: теге еллардагы караклар белән бу еллардагы каракларның статусын бутаганмын. Хәзерге караклар башка, аларга синең тәрәзә пәрдәләрең дә, кием-салымың да кирәкми. Алар я наркоманнар, я байлар, аларга байлыкларын арттыру өчен, наркотиклар алу өчен төсле металл кирәк. Алар төсле металл белән сату итәләр. Минем мунчадан да тимер-томырның ниндиен генә алмаганнар. Алюмин савыт-саба, баклар, помидор бәйләр өчен җиз таяклар, баскыч-стремянкалар, таслар дисеңме, мунча чүмеченә, кадакка хәтле иркенләп, берәмтекләп җыйнаганнар. Мунчам ялтырап тора: буп-буш калган. Электр самоварым бигрәк кызганыч. Мин аның борыны белән капкачын өйдә яшереп калдырдым. Янәсе дә борынсыз самоварның кемгә кирәге бар? Анысы бер хәл. Ләгънәт суккан караклар, яраткан балтамны урлап чыкканнар. Ярты метр гына саплы, ялтырап торган уенчык кебек балта иде. Бүләк балта. Их караклар! Дөнья ямен беләсезмени соң сез!

Карак бер үзе генә булмаган булыр. Әнә, күршенең күгәрмәс металлдан эшләнгән мунча мичен дә сүтеп алып киткәннәр бит әле. Һәрхәлдә карак ялгызы гына түгел. Бакчаларны басучылар, километрлары белән тимерчыбыкларны өзеп, халыкны утсыз калдыручылар — болар нибары башкаручылары гына ич аның. Вак караклар. Заказ бирүче чын караклар төсле металлны кабул итү пунктларында утыралар, минемчә. Аннан да зур баш караклар югарыда утыралар. Алары инде дөнья корытучылар. Газеталардан укып белүебезчә, төсле металл караклары халык хуҗалыгына миллиард сумнар зыян китерәләр. Нефтьчеләргә, торак хуҗалыкларына, тимер юлларга, безнең ише гади халыкка — һәммәсенә. Уйласаң, исең-акылың китәр. Кызык бит, шәһәр янында йөри торган электричкаларның әйбер куя торган киштәләрен йолкып-йолкып алганнар. Кай арада диген. Электричкаларда тәүлек әйләнә кеше йөри ич!

Төсле металл җыю өчен җаваплы оешма җитәкчеләре ни карый? Илгә-көнгә шул оешма җитәкчеләренең булдыксызлыгы аркасында күпме зыян китерелә. Мин аларны, һич шикләнмичә, караклар белән бер арбага җигелгәннәр дияр идем. Эшеңне кешеләргә, илгә-көнгә зыян китермичә оештыра алмыйсың икән, ник урын биләп утырырга? Әгәр эш шулай дәвам итсә, илебез тиздән караңгылыкка чумачак: каракларга байлык туплау өчен көннән-көн күбрәк металл кирәк.

"Чаян" дус, яраткан балтам, самоварым турында да онытыр идем, зинһар, җитәкчеләрне төсле металл җыю эшен тәртипкә салырга өндә. Соңгы вакытта тагын яңа афәт кузгалган, имеш. Караклар хәзер су торбаларын да урлый башлаганнар, ди. Эш болайга китсә, ахыр заман киләчәген көт тә тор. Өмет синдә, Чаян!

Роза ХАФИЗОВА.

«ЧАЯН»
(«Скорпион»)
турындагы мәгълүмат Татарстан матбугаты каталогында һәм Россия Федерациясе матбугаты каталогында («Роспечать») бирелә. Россия каталогының 310 битен карагыз!

ЧАЯН
(CAJAN)

Татарча «Чаян»ның индексы – 73488,
Русча «Чаян» («Скорпион») индексы – 73489.

Читкә илтү чыгымнарын исәпләп, «Роспечать» каталогында «Чаян» бәясе – **53 сум 40 тиен.**
Татарстанда – **47 сум 40 тиен.**

Юмор илчесе

Себерләргә сөенеп барган,
Донбассларда эзле һаман,
Уралларда үрләр алган,
Тайгаларда юллар салган,
Чирмешәндә битен юган,
Ык буенда кибән куйган,
Чулман буен җырлап узган,
Иделләрдә колач салган, —
Кайда булса, шунда дуслар.
Фикердәшләр таба алган
«Чаян» — юмор илчесе —
Укы, татар кешесе!
Елмай, татар кешесе!



«ЧАЯН» ӨЕГЕЗГӘ КОЯШ БУЛЫП КЕРСЕН!

Аннан-моннан

* * *

Урам — «мәктәп» булган җирдә, койма — «язу тактасы».

* * *

Элек очучы-сынаучы булган, хәзер, «эчүче-сынаучы» яңа аракыларны беренче булып эчеп карый.

* * *

Комиссия киләсен ишеттегезме?
— Ишеттек.
— Юл буендагы сабакларга җеп белән эре кыярлар элеп чыктыгызмы?
— Чыктык.
— Ә хәзер шуларның саргылтларын яшелгә буягыз!..

Марс АХУНОВ.

КАЗАН.

Юрий МАКАРОВ

БЕЗДӘ ТӨРЛЕ ХӘЛЛӘР БАР...

БЕР ГЕНӘ НӘРСӘ КАЛДЫ

Ленка Кружкова сыра сата. Ире Сашка белән алар, авылча исәпләгәндә, таза яшиләр. Югыйсә, гаилә корып җибәргәннәренә биш кенә ел әле.

Вера түти үзенең ахирәтләре алдында шушы гаилә хакында тезепме тезә:

— Шулкадәр дә пар килсә килерләр икән! Күр син аларны: яратыштылар, кавыштылар, язылыштылар, әллә ничә балалары булды. Әнә нинди йорт салып куйдылар, хан сарае диярсең! Ишегалдында Сашканың бишекле матае тора. Резин көймәсе бар. Өреп кабарта да, күлдән көрәп балык тота. Үзем күреп тордым. «Волга» ук булмаса да әллә нинди генә чит ил машинасы сатып алды. Хәзер бер генә нәрсә калды...

— Ә нәрсә? — дип Алена Вера түтинең авызына карый.

Юридик сүз сөйләнешләрен яхшы белгән Вера түти ярып сала:

— Кән-фис-кә-вәйт итәргә!..

ЮАТТЫ

Егораша дәдәй туксанга җитеп килә инде. Әмма ул бик нык әле. Аны яшь чагында хатын-кыз артыннан бик күп чапкан дип сөйлиләр.

Менә алар колхоз экспедиторы Лешка белән, уртага бер ярты куеп, гәп куерталар. Лешка йөкне шактый кыек төяргә өлгергән һәм елардай булып бабайдан дөреслекне белергә маташа:

— Егор дәдәй, минем хатын Любаня әллә кемнәр белән йөри диләр... Нишләп шулай диләр? Бәлки дөресен әйтәләрдер, ә?

— Син, Алешка, андый гайбәтләрне тыңлама... — ди Егор дәдәй. Анары эчеп, артыннан кабып куя һәм Лешкага иелә төшеп, юаткыч сүзләр әйтә. — Әмма, Лешка, бу гайбәтләрдә күпмедер дөреслек бар...

КИТӘСЕЗ МЕНИ?

Паша Макухин атна буена эчеп йөри һәм, ниіаять, эшкә килә.

Аны хуҗасы чакыртып ала да, турыдан-туры әйтә:

— Ярар, Павел, синең белән хушлашырга туры килә...

Пашка тирләп чыга, куллары калтырый:

— Иван Николаевич, нәстә, бездән китәсез мени?..

РОВЕНЬКИ бистәсе,
БЕЛГОРОД өлкәсе.



А. ШУЛЬПИНОВ рәсеме.



ЧАЯН

САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
№ 12 (1488) 2001

Баш редактор
Рәшит ЗӘКИЕВ.

Редколлегия:

Ринат АБЗАЛОВ, Илдус АЗИМОВ, Александр АЛЕШИН (баш рәссам), Юрий БЕЛЯЙЧЕВ, Вячеслав БИБИШЕВ, Лия БОЧКОВА, Мәгъсум ГӘРӘЕВ, Эрнест ДЫШАЕВ, Минвәгыйз ЗӘЙНЕТДИНОВ (җаваплы секретарь), Зөлфәт МАЛИКОВ, Илдар НӘФИЕВ, Светлана ПРИВИНА, Виталий ФЕОКТИСТОВ, Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ, Петр ШАҺРАЙ (баш редактор урынбасары), Александр ШУЛЬПИНОВ.

«Чаян»га Татарстанда, Россиядә һәм БДБда барлык элемтә бүлекчәләрендә язылырга мөмкин.

УЧРЕДИТЕЛЬЛӘР:

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХӨКҮМӘТЕ, «ИДЕЛ-ПРЕСС» БАСМАХАНӘСЕ һӘМ «ЧАЯН» РЕДАКЦИЯСЕ.

Журнал Татарстан Республикасы матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары эшләре министрлыгында теркәлде.

Теркәлү саны — 81.

2001 ЕЛНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫНА ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ БӘЯСЕ — 47 сум 40 тиен (ТАТАРСТАНДА). ТАТАРЧА «ЧАЯН»НЫҢ ИНДЕКСЫ — 73488, РУСЧАСЫНЫКЫ — «ЧАЯН»(«Скорпион») — 73489.

Айга ике тапкыр татар һәм рус телләрендә чыга.

Белешмәләр өчен телефоннар:
43-50-32, 43-27-93, 49-36-16.

© «ЧАЯН», 2001.

«Идел-Пресс» басмаханәсе типографиясендә басылды. 420066, Казан, Декабристлар ур., 2. 1923 елдан чыга.

Басарга кул куелды 19. 06. 2001 ел. Тираж 8159. Заказ А-229. Кәгазь форматы 84 x 108 1/16. Офсет ысулы белән басыла. Басма табагы 2,1. Учетн.-изд. табагы 3,01.

Оригинал-макет "Jahat" программалар пакеты ярдәмендә җәһәт кенә әзерләнде.

«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.

Безнең Интернеттагы адрес:
http://www.almamater.ru/chayan
e-mail: chayan@mail.ru
e-mail: root@chayan.kazan.ru.

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2. «Чаян» редакциясе.

"ЧАЯН" АВТОКЛУБЫ

ШАРТЛАУ



А. ШУЛЬПИНОВ рәсеме.



Л. ЕЛЬКОВИЧ рәсеме.

И. ӘХМӘДИЕВ рәсеме.

